# Татарстан Республикасы ЗАКОНЫ

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

**1 статья.** «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11–12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 11) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. 3 статьяда:

түбәндәге эчтәлектә яңа 3 өлеш өстәргә:

«3. Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы Конституциясенә аңлатма бирә»;

моннан соңгы өлешләрнең номерларын тиешенчә үзгәртергә.

2. 39 статьяда:

2 өлешкә түбәндәге эчтәлектә яңа 3 пункт өстәргә:

«3) Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләмәләрен аңлауда килеп чыккан билгесезлек»;

3 пунктны 4 пункт дип санарга.

3. 40 статьяның 2 өлешендәге 6 пунктка «Татарстан Республикасы Конституциясенең аңлатма бирелергә тиешле нигезләмәсе турында;» дигән сүзләрне өстәргә.

4. 41 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктка «яисә Татарстан Республикасы Конституциясенең аңлатма бирелергә тиешле нигезләмәсе;» дигән сүзләрне өстәргә.

5. 66 статьяда:

2 өлешендә:

«икенче» сүзеннән соң «, өченче» сүзен өстәргә;

«дүртенче» сүзен «бишенче» сүзенә алмаштырырга;

3 өлешендә «өченче» сүзен «дүртенче» сүзенә алмаштырырга.

6. 67 статьяның 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Конституциясенә аңлатма бирү турында, шулай ук Татарстан Республикасы Президентының гамәлләре һәм карарлары Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турында карарлар, әгәр судьяларның гомуми санының кимендә өчтән ике өлеше тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала».

7. Законга түбәндәге эчтәлектә яңа XII бүлек өстәргә:

«Татарстан Республикасы Конституциясенә аңлатма бирү турындагы эшләрне карау

93 статья. Татарстан Республикасының Конституция судына мөрәҗәгать итү хокукы

Татарстан Республикасының Конституция судына Татарстан Республикасы Конституциясенә аңлатма бирүне сорап мөрәҗәгать итү хокукына Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, аның даими комиссияләре, Татарстан Республикасы халык депутатларының биштән бере, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Парламент контроле комитеты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы Югары суды ия була.

94 статья. Татарстан Республикасы Конституциясенә аңлатма бирүнең мәҗбүрилеге

Татарстан Республикасы Конституциясенә Татарстан Республикасының Конституция суды биргән аңлатма хакимиятнең барлык вәкиллекле, башкарма һәм суд органнары, җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, урындагы затлар, гражданнар һәм аларның берләшмәләре өчен мәҗбүри була».

8. XII–XIV бүлекләрне XIII–XV бүлекләр дип санарга.

93–111 статьяларны 95–113 статьялар дип санарга.

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 28 июне
№948